Әбуль - Касим(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Касим атасы;
Әбут - Таһир(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Таһир атасы;
Әбут-Таййиб (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) -



www.darul-kutub.com

Таййиб атасы;
Әбу Ибраһим (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Ибраһим атасы;
Мушәффәгъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - шәфәгатьче;
Шәфигъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - шәфәгать иясе;
Салих (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изге күңелле, гамәлле;
Мүслих (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - төзәтүче;
Мүһәймин (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - саклаучы;
Садикъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - ихлас вә хаклык гына кылучы;
Мүсаддикъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - ышанычлык иясе;
Сыйдкъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - хаклык;
Сәййидүл – мүръсәлин (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - рәсүлләр әфәндесе;
Имәмүл - мүттәкыйн (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - тәкъвалыларның имамы;
Ка’идүл – Гуррил – мүхәҗҗәлин (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - гыйбадәт кылудан нурга чумган иман әһеле юлбашчысы
Халилүр-рахмән (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Рахман булучы Аллаһы Тәгаләнең иң якын дусы, ахыйрәт дусы;

Бәрръ (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изге күңелле;
Мәбәрръ(саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изгелек итүче;
Үәҗиһ (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - югары, хөрмәтле;
Нәсыйх(саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - игелеккә чакыручы;
Нә`сыйх (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - киңәш бирүче
Үәкил (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - вәкил;
Мүтәүәккил (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - тәвәккәлләүче;
Кәфил (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - кәфәләт кылучы;
Шәфикъ (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - шәфкатьле;
Мүкыймүс-сүннәһ (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - сөннәтне торгызучы;
Мүкаддәс (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изге;
Рухүл - кудүс (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изге рух;
Рухүл - хәккъ (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - хаклык рухы;
Рухүл-кыйстъ (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - гаделлек рухы;
Кәфи (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - җитәрлек булучы;
Мүктәфи (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - канәгать булучы;



www.darul-kutub.com

Бәлиг (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - балигъ, кәмел;
Мүбәллиг (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - җиткерүче;
Шәфин (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)- шифаландыручы;
Үәсыйль (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - тоташтыручы;
Мәусуль (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - тоташтырган;
Сәбикъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - алдан булучы, килүче;
Сә’икъ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - алып баручы;
Һәди (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - туры юлдан алып баручы;
Мүһдин (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - бүләк ителгән;
Мукаддим (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - алдан килүче;
Гъазиз (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - гыйззәтле, көчле, хөрмәтле;
Фәдыйль (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - кәмел фазыйләтле булучы;
Мүфәддаль (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - яратылган;
Фәтих (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - ачып җибәрүче;
Мифтәх (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - ачкыч;



www.darul-kutub.com

Мифтәхүр - рахмәһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - мәрхәмәт ачкычы;
Мифтәхүл – җәннәһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - җәннәт ачкычы;
Гъаләмүл - имән (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - иман байрагы;
Гъаләмүл – йәкыйн (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - инану байрагы;
Дәлилүл – хайрат (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изгелекләргә дәлил;
Мүсаххихүл - хәсәнәт(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - игелекләрне сыйхәтләндерүче;
Мүкыйлүл - гъасәрат (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - авырлыкларны киметүче;
Сафүхүн гъаниз – зилләт (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - мыскылны гафу итүче;
Сахибүш - шәфәгъаһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - шәфәгать иясе;
Сахибуль - мәкам (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - мәкаме - мәхмүд иясе;
Сахибуль - кадәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изге басым иясе;
Мәхъсусул бил - гъыйзз (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - гыйззәт белән хасланган;
Мәхъсус бил - мәжд (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - данлык белән хасланган;
Мәхъсус биш –шәраф (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - шәрәфәт белән хасланган;
Сахибүл – үәсиләһ (салләл – лаһү галәйһи вә

сәлләм) - вәсиләһ аша Аллаһы Тәгаләгә ялвару иясе;
Сахибүс – сәйф (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - кылыч иясе;
Сахибүл - фәдыйләһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - фәзыйләт иясе;
Сахибүл - изәръ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изар иясе
Са`хибүл-хуҗҗәһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - олы дәлил иясе
Сахибүс - сүлтан (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Пәйгамбәрлек иясе;
Сахибүр - ридә' (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - чапан иясе;
Сахибүд - дәраҗәтир-рафигъаһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - югары дәрәҗә иясе;
Сахибүт – тәҗ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - таҗ иясе;
Сахибүл - мигфәръ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - сугыштагы баш кием иясе;
Сахибүл - лиүә`(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Хәмед байрагының хуҗасы;
Сахибүл - мигъраҗ(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Мигъраҗ кылучы;
Сахибүл - кадыйб (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - сугыш коралы иясе;
Сахибүл - бүрак (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Бурак хуҗасы;
Сахибүл - хатәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)

- пәйгамбәрлек мөһере иясе;

Сахибүл - гъаләмәһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - пәйгамбәрлек галәмәте иясе;

Сахибүл – бурһән (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - олы дәлил иясе;

Сахибүл - бәйән (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Коръән иясе;

Фәсыйхүл – лисән (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - күркәм телле;

Мүтаһһируль – җанән (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - йөрәкләрне, пакьлаучы;

Рауүф (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - йомшак күңелле;

Рахим (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - мәрхәмәтле;

Үзүнү хайр (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - изгелек, хәерлек колаклары;

Са`хибүл –исләм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Ислам иясе;

Сәййидүл - кәүнәйн (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - ике дөнья әфәндесе;

Гъайнүн - нәгъыйм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - нигъмәтлек чишмәсе;

Гъайнүл - гурр (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - данлык чишмәсе;

Сәгъдүл - лаһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - Аллаһы Тәгаләнең биргән бәхете;

Сәгъдүл – хальк (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - мәхлүкатларның бәхете;

Хатыйбүл -үмәм(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)



www.darul-kutub.com

- өммәтләрнең хатыйбы;
Гъаләмүл - һүдә`(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - тугры юл байрагы;
Кәшифүл - кураб (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - гамь-хәсрәтне куучы, юк итүче;
Рафигъур - рутәб (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - мәртәбәләрне югары күтәрүче;
Гъыйззүл - гъараб (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - гарәпләрнең гыйззәте;
Сахибүл-фәраҗ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) - котылу иясе (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм).

*******

## Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм)гә төрле җанварлар биргән исемнәр турында

Аллаһы Тәгалә Коръән - Кәримендә һәр җан иясе аерым бер өммәткә карый, аерым бер өммәтне тәшкил итә дигән. Әйтик, кырмыскалар аерым бер төркем яки өммәт. Судагы фәлән балык - башка бер төркем. Кешеләр - аерым бер төркем. Кешеләр төркеме гыйбадәт кылуларына карата аерым төркемнәрне, өммәтләрне тәшкил итәләр. Яһүдләр төркеме, нәсаралар төркеме, Мөхәммәд (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм) өммәте.
Һәр бер төркемдә Мөхәммәд (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)нең үз исеме бар икән.
Җәннәт халкы телендә Мөхәммәд (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)нең исеме башкача яңгырар.



www.darul-kutub.com

Аны - Гъабдүл-Кәри́м (Габделкәрим) дип атарлар. Җәһәннәм халкы телендә ул (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм) Гъабдүл - Җәббә́ръ (Габделҗәббар) булыр.

Гарше - Газыймне күтәреп торучы фәрештәләр Рәсүлебез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)не Гъабдүл-Хәми́д (Габделхәмид) дип атарлар.

Калган фәрештәләр Ахыр Заман пәйгамбәре (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)не Гъабдүл-Мәҗи́д (Габделмәҗит) дип атарлар.

Барча пәйгамбәрләр аңа (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)кә җәннәттә Гъабдүл-Уәһһәб (Габделваһһаб) дип дәшерләр.

Шәйтаннар Рәсүлебез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)не - «Гъабдүл-Каһһә́ръ (Габделкаһһәр) дип атарлар.

Җеннәр Рәсүлебез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм) не Гъабдүр-рахи́м (Габдеррахим) дип атарлар. Тау ияләре Рәсүл Әгъзам (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)не Гъабдүл-Халикъ (Габделхалик) дип атарлар.

Җир ияләре аны (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм) не – Гъабдүл-Ка́дир (Габделкадыйр), су ияләре – Гъабдүл-Мү́һәймин (Габделмөһәймин), балыклар – Гъабдүл-Куддүс (Габделкотдус), елан-чаяннар – Гъабдүл-Гаййәс (Габделгаяс) дип атарлар.

Кыргый хайваннар үз араларында сөйләшкәндә Рәсүлебез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)не Гъабдүр-раззә́къ (Габдеразак) диярләр.

Ерткычлар Рәсүлүллаһ (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)не Гъабдүс-сәлә́м (Габдесәлам) дип атарлар. Йорт малы Пәйгамбәребез (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)гә Гъабдүл-Му́ъмин (Габделмөэмин) дип дәшерләр.Кошлар исә, аңа (са́лләл-ла́һү га́ләйһи вә сә́лләм)кә Гъабдүл-Гаффә́ръ (Габделгафар) дип мөрәҗәгать итәрләр).

## Аллаһы Тәгалә вә Аның хәбибе (саллəл -лаһү галəйһи вə сəллəм)нең уртак исемләре

Мәгълүм булганча, Аллаһы Тәгаләнең күркәм, матур исемләре бар.
Пәйгамбәребез Мөхәммәд әл-Мостафа (саллəл - лаһү галəйһи вə сəллəм) бу хакта болай дигән:

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ قَالَ:

قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ:

إِنَّ لِلَّهِ تِسْعَةً وَتِسْعِينَ اسْمًا، مِائَةً غَيْرَ وَاحِدَةٍ،

إِنَّهُ وِتْرٌ يُحِبُّ الْوِتْرَ

مَنْ أَحْصَاهَا كُلَّهَا دَخَلَ الْجَنَّةَ



www.darul-kutub.com

هُوَ اللهُ الَّذِي لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الرَّحْمَنُ، الرَّحِيمُ،

الْمَلِكُ، الْقُدُّوسُ، السَّلَامُ، الْمُؤْمِنُ، الْمُهَيْمِنُ،

الْعَزِيزُ، الْجَبَّارُ، الْمُتَكَبِّرُ، الْخَالِقُ، الْبَارِئُ،

الْمُصَوِّرُ، الْغَفَّارُ، الْقَهَّارُ، الْوَهَّابُ،

الرَّزَّاقُ، الْفَتَّاحُ، الْعَلِيمُ، الْقَابِضُ، الْبَاسِطُ،

الْخَافِضُ، الرَّافِعُ، الْمُعِزُّ، الْمُذِلُّ،

السَّمِيعُ، الْبَصِيرُ، الْحَكَمُ، الْعَدْلُ، اللَّطِيفُ، الْخَبِيرُ،

الْحَلِيمُ، الْعَظِيمُ، الْغَفُورُ، الشَّكُورُ، الْعَلِيُّ، الْكَبِيرُ،

الْحَفِيظُ، الْمُقِيتُ، الْحَسِيبُ، الْجَلِيلُ، الْكَرِيمُ،

الرَّقِيبُ، الْمُجِيبُ، الْوَاسِعُ، الْحَكِيمُ، الْوَدُودُ،



www.darul-kutub.com

الْمَجِيدُ، الْبَاعِثُ، الشَّهِيدُ، الْحَقُّ، الْوَكِيلُ،

الْقَوِيُّ، الْمَتِينُ، الْوَلِيُّ، الْحَمِيدُ، الْمُحْصِي،

الْمُبْدِي، الْمُعِيدُ، الْمُحْيِي، الْمُمِيتُ، الْحَيُّ، الْقَيُّومُ،

الْوَاجِدُ، الْمَاجِدُ، الْوَاحِدُ، الصَّمَدُ، الْقَادِرُ، الْمُقْتَدِرُ،

الْمُقَدِّمُ، الْمُؤَخِّرُ، الْأَوَّلُ، الْآخِرُ، الظَّاهِرُ، الْبَاطِنُ،

الْبَرُّ، التَّوَّابُ، الْمُنْتَقِمُ، الْعَفُوُّ، الرَّءُوفُ،

مَالِكُ الْمُلْكِ، ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ،

الْوَالِي، الْمُتَعَالِي، الْمُقْسِطُ، الْغَنِيُّ، الْمُغْنِي،

الرَّافِعُ، الضَّارُّ، النَّافِعُ، النُّورُ، الْهَادِي،

الْبَدِيعُ، الْبَاقِي، الْوَارِثُ، الرَّشِيدُ، الصَّبُورُ



www.darul-kutub.com

«Хакыйкать ки, Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бардыр. Кем булса да шуларны исендә калдырып санап китсә, җәннәткә керер. Ул, Аллаһы Тәгалә, бер Үзе генә, так булучы һәм такны ярата. Ул - Аллаһы Тәгалә, Аннан башка бер илаһи Зат юктыр: Әр - Рахмә́н, Әр - Рахи́м, Әл - Мә́лик, Әл - Кудду́с, Әс - Сәлә́м, Әл - Му́ьмин, Әл - Мү́һәймин, Әл - Гъази́з, Әл - Җәббә́ръ, Әл - Мутә́кәббир, Әл - Ха́лик, Әл - Бә́ри, Әл - Му́саувир, Әл - Гаффәръ, Әл - Каһһәръ, Әл - Уәһһә́б, Әр - Раззә́къ, Әл - Фәтта́х, Әл - Гъали́м, Әл - Ка́бидъ, Әл - Бә́ситъ, Әл - Ха́фидъ, Әр - Ра́фигъ, Әл - Мүгъыйзз, Әл - Мүзилл, Әс - Сәми́гъ, Әл - Бәсыйр, Әл - Хә́кәм, Әл - Гъа́дль, Әл - Ләты́йф, Әл - Хаби́р, Әл - Хәли́м, Әл - Гъазы́йм, Әл - Гафу́р, Әш - Шәку́р, Әл - Гъалийй, Әл - Кәби́р, Әл - Хә́физ, Әл - Мугы́йс, Әл - Хәси́б, Әл - Җәли́л, Әл - Кәри́м, Әр - Ракы́йб, Әл - Мүҗи́б, Әл -Уәсигъ, Әл - Хәки́м, Әл - Уәду́д, Әл - Бә́гъыйс, Әш - Шәһи́д, Әл - Хә́ккъ, Әл-Уәки́л, Әл - Кау́вийй, Әл - Мәти́н, Әл - Мәҗи́д, Әл-Уә́лийй, Әл - Хәми́д, Әл - Му́хсый, Әл - Мүбдий, Әл - Мүгъыйд, Әл - Мүхйий, Әл - Мүми́т, Әл - Хәйй, Әл - Каййу́м, Әл - Уә́җид, Әл - Мә́җид, Әл - Уә́хид, Әс - Са́мәд, Әл - Ка́дир, Әл - Му́кътәдир, Әл - Му́каддим, Әл -Му́әххыйр, Әл - Ә́үвәл, Әл - Ә́хыйр, Әз - За́һир, Әл - Бә́тыйн, Әл - Уә́лий, Әл - Мүтәгъа́ль, Әл - Би́рр, әт - Тә́увәб, Әл - Му́нтәкыйм, Әл - Гъа́фу, Әр - Рауф, Мә́ликүл - му́лк, Зүл - Җәлә́ли үәл - Икра́м, Әл - Му́късит, Әл - Җә́мигъ, Әл - Ганий, Әл - Мүгний, Әл- Мә́нигъ, әд - Да́рр, Ән - Нә́фигъ, Ән - Ну́р, Әл

- Һә́дий, Әл - Бәди́гъ, Әл - Бә́кый, Әл - Уә́рис, Әр - Раши́д, Әс - Сабу́р» (Бу хәдис – шәриф әл - Бохари вә Мөслим җыентыкларында китерелгән)

Коръәни Кәрим аятьләрендә, Кәлимә – и шәһадәттә, азан әйткәндә Аллаһы Тәгаләнең исеме янында Аның хәбибе, Пәйгамбәребез Мөхәммәд әл - Мостафа (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) исеме дә әйтелә. Бу – Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә хәзрәтләренең сөекле бәндәсе Мөхәммәд әл - Мостафа (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм)гә карата булган олы илаһи хөрмәт күрсәткечләре. Моннан тыш, Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең сөекле бәндәсенә карата булган илаһи мәхәббәтнең күрсәткечләреннән тагын бер төрлесе, Халикъ Тәгаләнең һәм Мөхәммәд әл - Мостафа (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм)нең уртак исемләре булудадыр. Бу исемләрнең хикмәте шундадыр ки, әгәр югарыда китерелгән һәр илаһи исемгә бәндә «Гъабд» ( «Габд») яки «кол» сүзен кушырга тиеш булса, уртак исемләргә карата бу таләп таралмас. Ул уртак исемләр киләсе була:

Әр-Рахи́м,Әл-Мү́һәймин,Әл-Гъази́з,Әл-Җәббә́ръ,Әл-Мүтә́кәббир,Әл-Кәри́м,Әш-Шә́һид,Әл - Хә́ккъ,Әл - Уәки́л,Әл - Кау́ийй,Әл - Мәти́н,Әл - Мүхйий,Әл - Мү́каддим,Әл - Уә́лий,Әл - Бәрр,Әл - Гъә́фуү,Әр - Рауф, Әл - Җә́мигъ, Әл - Кәфил, Әл - Мүҗиб. Тик Пәйгамбәребез Мөхәммәд әл-Мостафа (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм)гә карата бу исемләр кулланганда “әл” күрсәткечсез кулланырлар һәм бу очракта алар:

Рахи́м, Му́һәймин, Гъази́з,Җәббә́ръ, Мутә́кәббир, Кәри́м,Шә́һид,Хә́ккъ,Уәки́л,Кау́ийй,Мәти́н,Мухй ий,Му́каддим,Уә́лий,Бәрр,Гъа́фуў, Рауф, Җә́мигъ, Кәфил, Мужиб дип янгырарлар.

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд әл-Мостафа (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең тормышы: һәр мөселман бәндәсе белергә тиешле өстәмә мәгълүмәт

Рәсүлүллаһ(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Фил елы дип атала торган елны, Рабигъ әл-әүвәл аеның 12 нче көнендә дөньяга килә.

Туган көне – дүшәмбе була. Шуңа күрә Рәсүлүллаһ(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нән халык аның дүшәмбе көнне тота торган нәфел ураза турысында сорагач, ул (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм):

سُئِلَ النَّبِيُّ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ

عَنْ صَوْمِ الاِثْنَيْنِ فَقالَ:

فيهِ وُلِدْتُ وَ فيهِ أُنْزِلَ عَلَيَّ



www.darulkutub.com

“Ул көнне – мин тудым һәм дә үземә Коръән иңә башлады”, - дип җавап биргән.

Без, мөселманнар, Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең туган көнен яки Мәүлед – шәрифен елга бер мәртәбә үткәреп алсак, Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) үзе, Аллаһы Тәгаләгә шөкеранә йөзеннән, туган көнен олылап, уразалар тотып, елына аны илле мәртәбә үткәргән дип әйтү хаклы булыр!

Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) туар алдыннан:

- төнлә Кәгъбәтуллаһ эчендәге потлар йөзтүбән авалар;
- Фарсы (Иран) падишаһы сараеның тора торган җире хәрәкәткә килеп йөри башлый, 14 матча баганасы ауган,
- фарсыларның моңа кадәр бер дә сүнмәгән «изге» утлары сүнгән;
- Сәвәһ исемле күл корып куя.

Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) корсакта булган чакта аның атасы вафат була. Алты яшенә җиткәч Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең әнисе, Әминә абыстай вафат булган.

Шуннан соң, Пәйгамбәрәебез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)не бабасы Габдель - Мотталиб тәрбия кыла.

Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) гә 8 яшь, 2 ай һәм 10 көн җиткәч бабасы да вафат була һәм аны ата ягыннан бертуган булган Әбу



www.darul-kutub.com

Талиб агасы үз карамагына ала.
12 яшь, 2 ай һәм 10 көн тугач Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) агасы Әбу Талиб белән бергәләшеп Шәм Шәриф сәфәренә чыгалар. Шәм Шәриф хәзерге Сүрия җирләре була.
Бусра исемле шәһәргә җиткәч аларны,дөньядан ваз кичкән, исе китмәгән , Бәхирә исемле галим карт очрата.
Ахыр Заман Пәйгамбәрен китапларда тасвирлаган сыйфат - кыяфәт буенча танып аны (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) кулыннан ала һәм: «Бу – Галәмнәрнең Тәрбиячесенең рәсүле. Аллаһы Тәгалә аны галәмнәргә илаһи мәрхәмәтен ачыклау ягыннан җибәргән. Бу урыннан кузгалгач аңа сәҗдә кылмый торган таш һәм агач калмас. Ташлар - агачлар исә пәйгамбәр каршында гына сәҗдә кылырлар. Без (әһле китап) аның турында шундый кыяфәттә тасвирланган килеш китапларыбызда мәгълүмәт табабыз», - дип әйтә.
«Әгәр син аның белән бу урыннан Шәм Шәрифкә кузгалсаң, яһүдләр аны үтерерләр»,– дип кисәткәч, хз. Әбу Талиб һәм яшь Мөхәммәд (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Мәккәгә кайтыр юлга чыгалар.
Икенче мәртәбә хәзрәте Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Шәм Шәрифкә хәзрәте Хадиҗә (разыял – лаһү ганһә)нең хезмәтче малае Мәйсәрә белән бергә сәүдә эшләре белән юл тоткан.
Бусра шәһәренә кергәч Пәйгамбәр (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Бәхирә картның тора торган



www.darul-kutub.com

урыны янындагы бер агачның шәүләсендә ял итә. Бәхирә карт бу хәлне күреп: «Бу агач шәүләсендә пәйгамбәрдән башка беркемдә ял итмәс!», - дип икърар кылган.

Мәйсәрә исә өйлә белән икенде арасында һәм эсселек арткан саен аның өстендә ике фәрештә иңеп канатлары белән шәүлә биреп торалар иде диеп сөйләгән.

Шушы сәфәрдән кайткач, Рәсүлүллаһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) хәзрәте Хадиҗә( разыял – лаһү ганһә) белән никахләшә.

Пәйгамбәр(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)гә бу вакытта 25 яшь, 2 ай һәм 10 көн туган була.

Утыз биш яшь тулгач Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Кәгъбәтүллаһ төзәтү - яңарту эшләрендә катнаша һәм мөбәрәк куллары белән Кара ташны махсус урынына урнаштыра.

40 яшь тулып бер көн узгач Рәсүлүллаһ (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Хира мәгарәсе эчендә булганда, аның янына, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, Җәбраиль фәрештә (галәйһис – сәлам) килә. Мөхәммәд (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең пәйгамбәрлеге Рамазан Шәриф аенда башлана. Бу көн – дүшәмбе көне булган. Шуннан соң, 3 ел буена Мөхәммәд (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) һәм аның әһле – бәйте кирам Мәккә кәферләренең дошманлыгы вә чолганышында үткәрәләр. 3 ел буена аралашу, туганлашу, алыш-бирешләр тукталган була. Бу гаять авыр чор тәмамланган заманда Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи

www.darul-kutub.com

вә сәлләм)гә 49 яшь иде. Шуннан соң 8 ай һәм 3 атна вакыт узгач, Пәйгамбәребез (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең абые, хәзрәте Әбу Талиб, вафат була, аннан соң 3 көн үтә дә хәзрәте Хадиҗә абыстай( разыял – лаһү ганһә)дә вафат була.

50 яшь тулып 3 ай узгач, Пәйгамбәребез (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) янына Нәсыйбиннән җеннәр килеп, Ислам динен кабул итәләр.

51 яшь тулып 9 ай үткәч, ул (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Зәмзәм суы белән Мәкаме Ибраһим арасында булган урыннан күккә күтәрелеп Кодыс Шәрифкә (Иерусалим) сәяхәт кыла.

Бу сәяхәт «әл-Исра'» дип атала.

Мәккә-и Мөкәррәмәдән күтәрелеп Рәсүле Мөхтәрәм(саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Җәбраиль( галәйһис – сәлам) фәрештәнең хөсне-нәсыйхәте белән киләчәктә яшәячәк Тыйбәһ (Таййибәһ) шәһәренә, шуннан Муса (галәйһис – сәлам)нең Аллаһы Тәгаләдән Тәурат бәхетенә ирешкән Сәйнә тавына, шуннан соң Гайсә (галәйһис – сәлам) туган Бәйт Ләхем шәһәренә төшеп һәр кайсысында икешәр рәкәгать тәхийййәт намазларын укуы мәгълүм.

Кодыс Шәрифтә Рәсүл Әкрәм (саллəл – лаһү галәйһи вә сәлләм) әл-Бурак исемле бер гаҗәеп хайван өстенә утырып күккә күтәрелә. Җиденче кат күккә күтәрелгәч, хәтта Җәбраиль( галәйһис – сәлам) җитә алмаган урынга җитеп, Аллаһы Тәбәрәкә вә Тәгалә хәзрәтләре белән сохбәт кыла. Шунда илаһи бүләкләргә ирешә, өммәтенә намаз



www.darulkutub.com

фарыз ителә. Сәяхәтнең бу өлеше «әл-Мигъраҗ» дип атала.

53 яшькә җиткәч Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) Мәккә-и Мөкәррәмәдән Мәдинә-и Мөнәввәрәгә һиҗрәт кыла.

Бу вакыйга Рабигъ әл - Әүвәл аеның 21–22 көннәрендә, дүшәмбе көнне була. Мәдинә-и Мөнәввәрәгә Нәбийе Мөхтәрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) дүшәмбе көнне килеп керә. Мәдинә-и Мөнәввәрәдә Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) 10 ел үткәрә һәм шунда ул (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) җан тәслим кыла.

## ПӘЙГАМБӘР ГАЛӘЙҺИС-СӘЛАМНЕҢ МИЛЛӘТЕ ҺӘМ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ

Хәзрәти Сәгъд ибне Әбү Вәккас разыйәл - лаһү ганһе әйтүенчә, Пәйгамбәр (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм) Мәдинәгә килеп җиткәч аның янына (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) Җүһәйнә кабиләсе кешеләре килә дә: «Син безнең яныбызга килеп урнаштың, безгә ышаныч күрсәттең, без сиңа иминлек булдырабыз, син дә безне иминлектә сакласаң иде!», - дип мөрәҗәгать итәләр.

Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм): «Нәрсә өчен шулай сорыйсыз?», — дип сорагач алар: «Безгә тынычлык, иминлек кирәк», - дип җавап бирделәр. Шул вакыт Раббуль-Гыйззә



www.darul-kutub.com

لَقَدْ جَآءَكُمْ رَسُولٌ مِنْ اَنْفُسِكُمْ عَزِيزٌ عَلَيْهِ مَا عَنِتُّمْ
حَرِيصٌ عَلَيْكُمْ بِالْمُؤْمِنِينَ رَؤُفٌ رَحِيمٌ ﴿١٢٨﴾

Инде сезгә үз арагыздан рәсүл килде. Сезнең гөнаһ кылуыгыз аңа авыр! Ул сезнең турыда бик кайгырта, иман китереп инанучыларга карата йомшак, күңелле, рәхимле! (әт-Тәүбәһ, 128) аятен иңдерә.

## БУ АЯТЬНЕҢ ТӘФСИРЕ

Хәзрәти Катәдә бу аятьне аңлатканда болай дигән:

جَعَلَهُ اللّٰهُ مِنْ اَنْفُسِهِمْ

فَلاَ يَحْسُدُونَهُ عَلٰى مَا اَعْطَاهُ اللّٰهُ

مِنَ النُّبُوَّةِ وَ الْكَرَامَةِ

عَزِيزٌ عَلَيْهِ عَنِتَ مُؤْمِنِهُمْ

حَرِيصٌ عَلٰى ضَالِّهِمْ اَنْ يَهْدِهِ اللّٰهُ

«Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһис-сәламне аларның яки гарәпләрнең үз арасыннан булдырды,



www.darul-kutub.com

Пәйгамбәр итеп җибәрде, шуңа күрә Аллаһы Тәгалә аңа биргән пәйгамбәрлеккә, могҗизаларга көнләшә күрмәгез! Ул (саллəл-лаһү галәйһи вә сәлләм) мөэминнәрнең хәл - әхвәлләре турында бик борчылып тора, Аллаһы Тәгалә кәферләрне дә туры юлга бастырмас микән дип әрнеп тора...»

Рәсүл Әкрам (саллəл-лаһүгаләйһи вә сәлләм) янына Җәбраил фәрештә галәйһис-сәлам бер фәрештә белән бергәләшеп киләләр һәм Аллаһы Тәгаләдән аңа сәлам тапшырган:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ :

جاءَ جِبْرِيلُ عَلَيْهِ السَّلامُ فَقالَ :

يا مُحَمَّدُ اِنَّ رَبَّكَ يُقْرِئُكَ السَّلامَ

وَ هَذا مَلَكُ الْجِبالِ قَدْ اَرْسَلَهُ

اللهُ اِلَيْكَ وَ اَمْرُهُ لا يَفْعَلُ شَيْئًا

اِلَّا بِأمْرِكَ

فَقالَ لَهُ مَلَكُ الْجِبالِ :



www.darul-kutub.com

اِنَّ اللّٰهَ اَمَرَنِي اَنْ لا افْعَلُ شَيْئًا

اِلَّا اَمْرِكَ

اِنْ شِئْتَ دَمْدَمْتُ عَلَيْهِمُ الْجِبالُ

وَ اِنْ شِئْتَ رَمَيْتُهُمْ بِالْحَصْباءِ

وَ اِنْ شِئْتَ خَصَفْتُ بِهِمُ الْاَرْضُ

قالَ : يا مَلَكَ الْجِبالِ

فَاِنِّي آنى بِهِمْ لَعَلَّهُ انْ يَخْرُجُ

مِنْهُمْ ذُرِّيَتُهُمْ يَقولوا لا اِلَهَ اِلَّا اللّٰهُ

فَقالَ مَلَكُ الْجِبالِ:

انْتَ كَما سَمَّاكَ رَبُّكَ رَؤُوفُ رَحيمٌ

www.darul-kutub.com

һәм «Йә, Мөхәммәд! Раббың сиңа сәлам тапшыра! Һәм дә бу фәрештәне сиңа иңдерә. Бу фәрештә тауларга хуҗа булучы фәрештә. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре аңа син (галәйһис-сәлам) нәрсә сорасаң да шуны үтәргә дип кушып җибәрде!» дигән.Шуннан тауларга хуҗа булучы фәрештә: «Йә, Мөхәммәд Аллаһы Тәгалә миңа нинди генә әмер итсәң дә шуны җиренә җиткерергә дип әмер итте. Әгәр син теләсәң, мин кәферләрнең өстенә тауларны атып бәрермен, теләсәң, аларны вак, чуерташ белән атып үтерермен, теләсәң, аларның астында җирне юк итәрмен!», — ди.Рәсүлуллаһ (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм): «Ий, тауларга хуҗа булучы фәрештә! Мин алар арасыннан «Лә иләһә илләл-лаһә» дип әйтүчеләр килеп чыкмасмы дип күзәтергә җибәрелгән Рәсүл буламын! Син аларга тимә!», - дигәч, фәрештә: «Чыннан да синең исемең йә, Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә үзеңне «рәүф, рәхим» (кызганучы, рәхимле) дип атаган исемеңә туры килә икән шул!», - дип хәйран калып әйтә.

Хәзрәти Ибне Габбас разыйәл-лаһү ганһүмә

وَقَدْ قالَ ابْنُ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُم:

لَيْسَ مِنَ الْعَرَبِ قَبيلَةٌ إلَّا وَ قَد وَلَدَت

النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ

مُضَرِيُّها وَ رَبيعِيُّها وَ يمانِيُّها

رواه عبد بن حميد وابن أبي أسامة وابن المنذر

«Пәйгамбәребез галәйhис-сәлам туып, аның катнашы булмаган гарәп кабиләсе калмады. Аның Мозарга да, рабигыйләргә дә, йәмәниләргә дә катнашы булды», — дигән.

Яки Пәйгамбәр галәйhис-сәлам нәсел - нәсәбендә hәр гарәп кабиләсенең каны булды дигән сүз. Шуңа күрә Пәйгамбәр галәйhис-сәлам белән бөтен гарәп кабиләләре әүвәл дә (яки Ислам Шәригате чорына кадәр дә), соңыннан да (Ислам шәригате чорында да hәм ул (салләл-лаhү галәйhи вә сәлләм) вафат булгач та горурландылар hәм горурланалар.

Хәзрәти Гали Ибне Әбү Талиб кәррамәл-лаhү үәҗhәh:

عَنْ اَنَسٍ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُ :

قَرَأَ رَسُولُ اللّٰهِ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ

لَقَدْ جَاءَكُمْ رَسُولٌ مِنْ أَنْفُسِكُمْ

عَزِيزٌ عَلَيْهِ مَا عَنِتُّمْ

حَرِيصٌ عَلَيْكُمْ بِالْمُؤْمِنِينَ رَءُوفٌ رَحِيمٌ



www.darulkutub.com

فَقَالَ عَلِيُّ بْنِ اَبِي طَالِبٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ :

يَا رَسُولَ اللهِ , مَا مَعْنَى أَنْفُسِكُمْ

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ :

اَنَا اَنْفَسُكُمْ نَسَبًا وَ صِهْرًا وَ حَسَبًا

لَيْسَ فِيَّ وَلَا فِي آبائِي مِنْ لَدُنْ آدَمَ سِفَاحٌ

كُلُّها نِكَاحٌ

«Йә, Рәсүлуллаһ! Бу аятьтәге «әңфүсикүм» дигән сүзнең төп мәгънәсе нәрсә аңлата соң?», — дип Рәсүл Әкрам саллəл-лаһү галәйһи вә сәлләм сорагач, ул (галәйһис-сәлам): «Мин сезнең арагызда иң нәфис чыгышлы, иң нәфис кияү булучы һәм иң нәфис, кадерле дәрәҗә иясе булам. Миндә үземдә дә, Адәм атабыздан башлап ата-бабаларымда да никахсыз нәселләнү булмады, элекке нәселем дә һәрвакыт никах аша гына үрчеде», — дип аять эчтәлеген аңлатып бирә.



www.darul-kutup.com

## Рәсүл Әкрәм вә Нәбийе-Мөхтәрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең мөбәрәк кыяфәте

Пәйгамбәр(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең мөбәрәк йөзе бик матур, нур балкып тора торган була. Мөбәрәк тавышы һәм дә бик матур яңгырый торган тавыш булган.

Пәйгамбәр(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) шатланганын Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең мөбәрәк маңгаена карап аңларга була иде.

Төнлә ул(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) нәкъ көндез күргән шикелле күрә торган була.

Рәсүл Әкрәм(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк артында нәрсә булганны нәкъ алдында булганны күргән шикелле күрә торган була.

Ян - якка караганда Рәсүл Әгъзам (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) бөтен гәүдәсе белән борыла торган була.

Нәбийе-Мөхтәрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) күккә караганда җиргә күбрәк карап йөри торган була.

Мөбәрәк күзләре зур булган һәм аларда бераз кызгылт төсмер күрергә мөмкин булган.

Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) нең мөбәрәк күзләре кара төсле булган. Кичә саен Рәсүлебез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк күзләренә сөрмә сыза торган була.

Рәсүлебез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең



www.darulkutub.com

мөбәрәк маңгае ачык булган.
Күз карашлары нәзек кенә, бер берсеннән ерак булалар.
Мөбәрәк борыны бик күркәм булган.
Мөбәрәк башы зур булган.
Мөбәрәк авызы зур булган.
Мөбәрәк тешләре ап-ак һәм матур, бертигез булалар.
Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) сүзен бик матур, күркәм иттереп,җиренә җиткереп сөйли торган була.
Мөбәрәк авызыннан чыккан гүзәл сүзләре белән ул (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) кешеләрнең игътибарын җәлеп итә торган була.
Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) сөйли торган сүзен кәлимә – кәлимә итеп, тәфсилләп, күңелгә җитә торган итеп сөйләгән. Кайбер вакыт сөйләгәннең әһәмиятен күрсәтеп, сүзләрен,сүз тезмәләрен 3 мәртәбә кабатлый торган була. Моның хикмәте шунда ки, риваятьләргә күрә җәннәт халкы оҗмахта шулай сөйләшерләр димәктә.
Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) нең мөбәрәк тавышы еракан ишетелә торган була.
Мөбәрәк елмаюы тирә - юньне яктырта торган була.
Елаганда, көлгәндә Рәсүлебез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) кычкырып еламаган, кычкырып көлмәгән. Әмма, Коръән аятьләрендә җәһәннәм



www.darul-kutub.com

газабы, тәмуг турында сүз булса, яки өммәтенең гөнаһлары хакында сүз булса, яки Аллаһы Тәгаләдән куркып уйланулардан ул (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк күз яшьләрен чыгарып елый торган була.

Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) нең мөбәрәк бармаклары, учлары зур булган, мөбәрәк куллары нык булган.

Мөбәрәк җәсәде, тәне йомшак булса да көчле булган.

Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) урта буйлы булган.

Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) янында озын кеше дә озын булып күренмәгән.

Утырып торганда Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең мөбәрәк җилкәләре башка халык белән чагыштырганда киңрәк һәм зурырак булып күренгән.

Пәйгамбәри - Мөхтәрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нән һәрвакыт хуш, тәмле ис килеп торган.

Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) нең мөбәрәк чәчләре, сакалы дулкын сымак булган.

Вакыт-вакыт мөбәрәк чәчләре озынбулган, вакыт-вакыт ул (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) аларны кыскарткан.

Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) һич беркайчан да чәчләрен буямаган.

Җан тәслим кылганда аның (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк сакалы белән чәчләрендә арасында бары тик 20 агарган мөбәрәк бөртекләр



www.darul-kutub.com

була.
Мөбәрәк мыекларының буе мөбәрәк кашлары буеннан аерылмаган.
Янында һәрвакыт мисвак яки теш чистарткыч һәм тарак йөрткән.
Мөбәрәк куллары белән Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк сакал-чәчләрен үзе тарый торган була.
Җәяү йөргәндә Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) ян - якка карамыйча, туры гына, аяк очларына карап йөри торган була.
Аның (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) үткән урыннарын һавада калган хуш ис буенча аңлап булган.
Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) милләте буенча гарәп булган.
Пәйгамбәребез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк тән төсе алсуырак төстә, күркәм, чибәр, матур, аксыл, нурлы булган.
Шәригать хөкеме буенча Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)не кара төсле, кара дип әйтүче кеше кәфергә әйләнә, әл-гъайәзү бил-ләһи! Чын гарәпләр аксыл, арыш төсле булалар.
Аллаһы Тәгаләнең халиле, Ибраһим (галәйһис - сәлам) үзе дә ак төсле, әтисе,Тарух та ак төсле булалар.
Ибраһим (галәйһис - сәлам) нең үги атасы яки Азәр кара төсле булган.
Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең мөбәрәк

җаны аның булачак сүрәтенә кертелгәч, булачак җан ияләре Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)не зиярат кылдылар һәм аны күрү белән мөшәррәф булдылар.

Шулай, аны күрүчеләрдән бәгъзе берләре аның мөбәрәк башын күрделәр.

Дөньялыкта, алар ул заманда бу хикмәтнең дәрәҗәсенә ирешкәнгә күрә, падишаһ булдылар яки булачаклар.

Маңгаен күргәннәр гадел түрә булдылар.

Мөбәрәк ике күзен күргәннәр Коръән хәфизләре булдылар.

Мөбәрәк ике яңагын күргәннәр гакыллы вә ихлас-яхшылык кылучы булдылар.

Мөбәрәк иреннәрен күргәннәр вәзир булдылар.

Мөбәрәк борынын күргәннәр табиб, хаким тотучы булдылар.

Мөбәрәк тешен күргәннәр күркәм йөзле булдылар.

Мөбәрәк телен күргәннәр падишаһларның илчеләре булдылар.

Мөбәрәк бугазын күргәннәре вәгазь кылу-чылар һәм мөәззин булдылар.

Мөбәрәк муенын күргәннәр сатучы булдылар.

Мөбәрәк сакалын күргәннәр газилар - бәһадирлар булдылар.

Мөбәрәк ике беләген күргәннәре укчы булдылар.

Мөбәрәк уң беләген күргәннәре кан алучы булдылар.

Мөбәрәк сул беләген күрүчеләр надан булдылар.

Мөбәрәк уң учын күргәннәре акча алмаштыручы булдылар.
Мөбәрәк сул учын күргәннәре үлчәүче булдылар.
Мөбәрәк ике кулын күргәннәре юмарт булдылар.
Мөбәрәк уң кул аркасын күргәннәре – ашчы булдылар.
Мөбәрәк сул кул аркасын күргәннәре саран булдылар.
Мөбәрәк уң кулының бармак башларын күргәннәре язучы булдылар.
Мөбәрәк уң кулының бармакларын күргәннәре тегүче булдылар.
Мөбәрәк сул кулының бармакларын күрүчеләр тимерче булдылар.
Мөбәрәк күкрәген күрүчеләр – галим мөҗтәһид булдылар.
Мөбәрәк аркасын күрүчеләр шәригать иясе булдылар.
Мөбәрәк кабыргаларын күрүчеләр – гази, корсагын күрүчеләр канәгать булучы, тәкъвә булдылар.
Мөбәрәк ике тезен күрүчеләр рәкүгъ вә сөҗүд кылучы булдылар.
Мөбәрәк ике аягын күрүчеләре аучы булдылар.
Мөбәрәк табан астын күрүчеләр күп йөрүче булдылар.
Мөбәрәк күләгәсен күрүчеләре җырчы булдылар.
Мөбәрәк һич бер җирен күрмәгәннәре – яһүди, нәсара һәм кяфер, мәҗүси булдылар.
Рәсүл Әкрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) мөбәрәк тәкәбберлек кылып, өсләренә

карамаганнары илаһлык дәгъва кылучы булдылар яки Фиргавен, Нәмруд, Гад, Сәмуд, Дәкыянус шикелле булдылар.

## Рәсүл Әкрәм вә Нәбийе-Мөхтәрәм (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең Хилйә - и Шәрифе

Мәгълүм булганча, Шәригате - Гаррә яки Ислам дененең пакь кануны жанвараларны, җан ияләрен тасвирлауны, аларның рәсемләрен ясауын хәрам кылган.Әмма һәр мөселман бәндәсе, Кыямәт көненә түзмичә, дөньяда ук сөекле Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм) не үз күзләре белән күрәсе килә.Бу максатка ирешү өчен олы хәзрәтләребез Хилйә - и Шәрифкә мөназара кылу яки күз карашын салып Хилйә - и Шәриф дип атала торган махсус бер язмага карауны киңәш иткәннәр. Хилйә - и Шәриф дип Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең сыйфатларын тасвирлаучы шәмаиль шикелле язма атала. Бу язмада Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең мөбәрәк кыяфәте, күренеше. мөбәрәк холкы вә сыйфатлары тасвирланган. Ул язманы бик матур иттереп язганнар, бизәкләгәннәр. Шушы язмага олы хөрмәт белән күз салучы кеше нәкъ Пәйгамбәребез (салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең үзенә караган шикелле, нәкъ аны үзен, (галәйһис - сәлам)не дөньяда ук күргән шикелле булыр.



www.darul-kutub.com

# بسم الله الرحمن الرحيم

أبو بكر رضي الله عنه

عمر رضي الله عنه

عن علي بن أبي طالب رضي الله عنه
كان إذا وصف النبي صلى الله عليه وسلم قال
لم يكن بالطويل الممغط ۞ ولا بالقصير المتردد ۞ كان ربعة
من القوم ۞ ولم يكن بالجعد القطط ۞ ولا بالسبط ۞ كان
جعدا رجلا ۞ ولم يكن بالمطهم ۞ ولا بالمكلثم ۞ وكان
في وجهه تدوير ۞ أبيض مشرب ۞ أدعج العينين ۞ أهدب
الأشفار ۞ جليل المشاش والكتد ۞ أجرد ذو مسربة ۞
شثن الكفين والقدمين ۞ إذا مشى تقلع كأنما
يمشي في صبب ۞ وإذا التفت التفت

عثمان رضي الله عنه

علي رضي الله عنه

# وما أرسلناك إلا رحمة للعالمين

معا ۞ بين كتفيه خاتم النبوة ۞ وهو خاتم النبيين ۞ أجود الناس
صدرا ۞ وأصدقهم لهجة ۞ وألينهم عريكة ۞ وأكرمهم عشرة
من رآه بديهة هابه ۞ ومن خالطه معرفة أحبه ۞ يقول ناعته لم أر قبله
ولا بعده مثله صلى الله عليه وسلم ۞ اللهم صل وسلم وبارك على نبي
الرحمة وشفيع الأمة محمد وآله وأصحابه أجمعين الطاهرين ۞ سوده محمد فؤاد

Алдагы биттә мәшһүр Хилйә - и Шәриф сүрәтен урнаштырдык. Бу Хилйә - и Шәрифнең эчтәлеге киләсе була: " Хәзрәте Гали ибне Әбу Талиб разыял - лаһү ганһе Рәсүлүллаһ (саллэл-лаһү галәйһи вә сәлләм)не тасвирлап болай диде:«Ул озын да, тәбәнәк тә түгел иде, урта буйлы иде. Чәчләре бөдрә дә, туры да булмаенча, дулкынланып торучан иде. Йөзе итләч тә, зур яңаклы да булмаенча, түгәрәк иде. Йөзе ак булып, яңаклары алсу, күзләре кара, кашлары исә озын иде. Җилкәләре киң булып, эре сөякле, тәнендә төкләр юк иде. Кул чуклары һәм табаны да зур иде. Барган чагында, аягын җирдән таудан төшкән кебек күтәрә иде, борылганда исә бөтен гәүдәсе белән борыла иде. Калак сөякләре арасында Пәйгамбәрлек мөһере булып, Пәйгамбәрләрнең иң соңгысы, кешеләрнең иң юмарты һәм кыюы иде. Кешеләрдән иң туры сөйләүчеләрдән булып, иң ышанычлысы һәм иң йомшагы иде. Аны күргән кешедә көтмәгәндә хөрмәт хисе уяна иде, белмәгәннәр ярату хисе кичерәләр иде, аны тасвирлаучы исә : «Мин аңа охшаганны аңа хәтле дә, аннан соң да күрмәдем», -дип әйтер. Йә, Аллаһым! Мәрхәмәт пәйгамбәре вә өммәтнең шәфәгатьчесе Мөхәммәд (галәйһис - сәлам)гә, аның әһеленә, сахәбәләренә салават, сәлам, бәрәкәт булсын!

Янә, хәзрәти Гали кәррамәл-лаһү үәҗһәһ риваятендә бер хәдис-шәриф очрый. Пәйгамбәр (галәйһис-сәлам), аның ишетүенчә, болай дигән була:

عَنْ عَلِيِّ بْنِ ابي طالِبٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ:

انَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قالَ :

خَرَجْتُ مِنْ نِكاحٍ وَلَمْ اَخْرُجْ مِنْ سِفاحٍ

مِنْ لَدُنْ آدَمَ اِلَى اَنْ وَلَدَني ابي وَ اُمّي

لَمْ يُصِبْني مِنْ سِفاحِ الْجاهِلِيَّةِ شَيْءٌ

«Мин никахтән дөньяга чыктым, һич никахсез хәлдән тумадым.
Адәм атабыздан башлап атам – анам үземне тудырганчы җәһеллек чорының фәхешеннән үземә һич бер нәрсә дә кагылмады»

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُما قالَ:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ :

لَمْ يَلْتَقِ ابَوايَّ قَطّ عَلَى سِفاحٍ ,



www.darul-kutub.com

لَمْ يَزَلِ اللهُ يَنقُلُني مِنَ الْاَصْلابِ الطَّيِّبَةِ

اِلَى الْارْحامِ الطَّاهِرَةِ مُصَفًّى مُهَذَّبًا ,

لا تَتَشَعَّبُ شُعْبَتانُ اِلَّا كُنْتُ في خَيْرِهِما

Икенче бер хәдис - шәрифтә болай диелгән:
«Минем әтием - әнием һич азгынлык нигезендә очрашканнары булмады.
Аллаһы Тәгалә мине пакьләп, сыйфатлап хуш ата умырткасыннан пакизә карынга күчереп дөньяга китерде.
Һәрвакыт бер ботак (бер нәсел, ыру) икегә аерылганда мин аларның хәерлесендә кала торган идем».
Рәсүлебез(салләл – лаһү галәйһи вә сәлләм)нең бу хатирәсен хәзрәти Ибне Габбас (разыйәл-лаһү ганһүмә) тапшыра.
Шуннан, Рәсүлебез Мөхәммәд (галәйһис-сәлам):

إنَّ اللهَ اصْطَفَى كِنانَةَ مِنْ وَلَدِ إسْماعيلَ،

وَ اصْطَفَى قُرَيْشًا مِنْ كِنانَة،

وَ اصْطَفَى مِنْ قُرَيْشٍ بَني هاشِمٍ،

وَ اصْطَفَاني مِنْ بَني هاشِمٍ

«Хакыйкать ки, Аллаһы Тәгалә Ибраһим угылларыннан Исмәгыйльне якын күреп, яратып сайлады, Исмәгыйльнең нәселеннән Бәнү Кинәнәһне, Бәнү Кинәнәһ арасыннан Аллаһы Тәгалә корәйешләрне якын күрде, корәйешләрдән исә Бәнү Һәшимне сайлады, мине исә Ул Бәнү Һәшим арасыннан сайлап алды», — ди. Бу хәдис шәрифнең тапшыручысы Вәсиләһ Ибнел-Әскагъ «сайлады», «сайлап куйды» дигән сүздә «Аллаһы Тәгаләнең махсус теләгән, әмерен үтәр өчен билгеләнгән» дигән мәгънәне бирә дип күргән.

Хәзрәти Ибне Габбас (разыйәл-лаһү ганһүмә) болай дигән:

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُما قالَ:

اِنَّ قُرَيْشًا كانَتْ نورًا بَيْنَ يَدَيَّ اللهِ تَعالَى

قَبْلَ اَنْ يَخْلُقَ الْخَلْقَ بِأَلْفَيِّ عامٍ,

يُسَبِّحُ ذَلِكَ النُّورُ

وَ تُسَبِّحُ الْمَلائِكَةُ بِتَسْبيحِهِ



www.darul-kutub.com

فَلَمَّا خَلَقَ اللهُ آدمَ عَلَيْهِ السَّلامُ

أَلْقَى ذَلِكَ النُّورُ فِي صُلْبِهِ

Рәсүл Әгъзам (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм) аңлатуы буенча Аллаһы Тәгалә бөтен мәхлукларны ратканчы ике мең ел алдан киләчәк корәеш кабиләсен Үзенең алдында бер якты нур кыяфәтендә яраткан була.Бу нур һәрвакыт тәсбих әйтүдә була, аңа карап фәрештәләр дә шул тәсбихне әйтүгә керешәләр. Инде Аллаһы Тәгалә Адәм (галәйһис-сәлам)не яраткач, шул нурны аның эченә, аның сырт сөягенә тутыра.

Кем ул корәеш? Корәеш кабиләсе - гарәп кабиләләренең берсе. Аларның бу исем ияләре булуына сәбәпче булган кеше - Пәйгамбәребез (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) бабаларының берсе Кусай була. Ул, Мәккәгә килеп кергәч, күптөрле күркәм эшләр эшли һәм аңа Әл-Курши дип атама бирәләр. Шул заманнан бирле бу кабиләне «Корәеш кабиләсе» дип атап йөрткәннәр. Пәйгамбәребез (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм):

عَنْ مُعَاوِيَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ:



www.darulkutub.com

اَلنَّاسُ تَبَعٌ لِقُرَيْشٍ فِي هَذَا الْاَمْرِ

خِيَارُهُمْ فِي الْجَاهِلِيَّةِ خِيَارُهُمْ فِي الْاِسْلاَمِ اِذَا فَقِهُوا

وَ اللهِ لَوْ لاَ اَنْ تَبْطَرَ قُرَيْشٌ

لَاَخْبَرْتُهَا بِمَا لِخِيَارِهَا عِنْدَ اللهِ

«Кешеләр һәрнәрсәдә корәйшиләр белән бергә булырлар. Аларның җаһилият, наданлык заманасындагы асыллары гыйлемгә ирешсәләр (фикыһ белсәләр), Ислам заманасында да асыл булырлар...» - дигән. (Могавия ишеткән хәдис-шәриф).

Умм Һәни бинт Әбү Талиб (разыял - лаһү ганһә) риваять кыла:

عَنْ اُمِّ هَانِئٍ بِنْتِ اَبِي طَالِبٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ:

فَضَّلَ اللهُ قُرَيْشًا بِسَبْعِ خِصَالٍ لَمْ يُعْطِيهَا



www.darul-kutub.com

اَحَدًا قَبْلَهُمْ وَ لاَ يُعْطِيهَا بَعْدَهُمْ

اَلنُّبُوَّةُ فِيهِمْ وَ الْخِلاَفَةُ فِيهِمْ

وَالْحِجَابَةُ فِيهِمْ وَ السِّقَايَةُ فِيهِمْ

وَ عَبَدُوا اللهَ عَشْرَ سِنِينَ لَمْ يَعْبُدْهُ اَحَدٌ غَيْرُهُمْ،

وَ نُصِرُوا عَلَى الْفِيلِ، وَنَزَلَتْ فِيهِمْ

سُورَةٌ مِنَ الْقُرْآنِ لَمْ يُذْكَرْ فِيهَا اَحَدٌ غَيْرُهُمْ،

لِإِيلاَفِ قُرَيْشٍ

«Пәйгамбәр (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә корәйшиләрне 7 төрле нәрсә белән хөрмәтләде: «Мин үзем корәйшиләрдән, пәйгамбәрлек корәйшиләргә бирелде, хәлифәләр дә алардан булыр, хаҗилар турысында кайгырту, аларны су белән сыйлау хөрмәте дә аларга булды, Аллаһы Тәгалә аларга фил өстеннән җиңү бирде, башкалар Аллаһы

www.darul-kutub.com

Тәгаләгә гыйбадәт кылмаган заманда алар гына Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылдылар, Аллаһы Тәгалә алар турысында Коръәндә сүрә иңдерде».

Әнәс (разыял - лаһү ганһе) риваять кылган хәдис-шәрифтә болай диелә: «Без ансарлар арасыннан булучы берәүнең өендә булганда, Пәйгамбәр (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) килеп керде. Ул ишекнең ян - якларын тотып алып:

عَنْ اَنَسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ:

كنا في بيت رجل من الأنصار فجاء

رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ

حتى وقف فأخذ بعضادتي الباب

فَقَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ:

"اَلْاَئِمَّةُ مِنْ قُرَيْشٍ، وَلَهُمْ عَلَيْكُمْ حَقٌّ، :

وَلَكُمْ مِثْلَ ذَلِكَ مَا اِنِ اسْتَحْكَمُوا عَدَلُوا وَ



www.darul-kutub.com

إِنِ اسْتَرْحَمُوا رَحِمُوا وَ إِذَا عَاهَدُوا وَفَوْا

فَمَنْ لَمْ يَفْعَلْ ذَلِكَ مِنْهُمْ فَعَلَيْهِ لَعْنَةُ اللهِ

وَ الْمَلاَئِكَةِ وَ النَّاسِ اَجْمَعِينَ

«Имамнар (җитәкчеләр) корәйшиләрдән булырлар. Аларның сезгә карата хаклары булыр. Сезнең дә аларга карата хакларыгыз булыр, тик хакларыгыз шул чакта хак булыр, әгәр алар хөкем чыгарганда гаделлек белән хөкем чыгарсалар, рәхимлек сораганда рәхимле булсалар, ант биргәндә сүзләреңдә торсалар. Инде шулай эшләмәсәләр, аларга Аллаһы Тәгаләнең дә, фәрештәләрнең дә, бар кешеләрнең дә ләгънәте булыр»

عَنْ اَبِي جَعْفَرٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ:

لاَ تَقَدَّمُوا قُرَيْشًا فَتُضِلُّوا وَ لاَ تَاَخَّرُوا عَنْهَا فَتُضِلُّوا

خِيَارُ قُرَيْشٍ خِيَارُ النَّاسِ



www.darulkutup.com

شِرَارُ قُرَيْشٍ شِرَارُ النَّاسِ

وَالَّذِي نَفْسُ مُحَمَّدٍ بِيَدِهِ لَوْ لاَ اَنْ تَبْطَرَ قُرَيْشٌ

لَاَخْبَرْتُهَا بِمَا لَهَا عِنْدَ اللهِ

«Корәешләрне узарга тырышмагыз - адашырсыз! Алардан артта калырга да тырышмагыз - саташырсыз! Корәйшиләрнең асыллары - адәм балаларының асыллары булыр, иң әшәкеләре исә - кешеләр арасында иң әшәке булырлар...» (Әбү Җәгъфәр (разыял - лаһү ганһе) тапшырган)

Пәйгамбәребез (галәйһис-сәлам) корәйшиләр өчен дога кылган:

عَنْ عُبَيْدِ بْنِ عُمَيْرٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ :

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ:

اَللَّهُمَّ كَمَا اَذَقْتَ اَوَّلَهُمْ عَذَابًا فَاَذِقْ آخِرَهُمْ نَوَالاً

«Йә, Аллаһым! Әүвәлгеләренә газап тәмен татыткан кебек, ахыргыларына хәерле нәтиҗәләр



www.darul-kutub.com

тәмен татыт!» (Гобәйд ибне Гомәир(разыял - лаһү ганһе) тапшырган). Бу хәдисләрдән күренгәнчә, корәйшиләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан олы нигъмәтләргә ия булалар. Аллаһы Тәгаләнең йорты, Кәгъбәтүллаһ шушы Мәккә шәһәрендә булу сәбәпле, калган гарәп кабиләләре корәйшиләрне «Аллаһ йортының әһелләре» дип йөртә башладылар. Кабиләләр Кәгъбәтуллаһка, Мәккәгә килеп, анда яшәп, ашап - эчеп, Мәккә халкының көнлек ризыгын мөмкин кадәр җиңеллек белән кәсеп итүләренә дә сәбәп булалар. Шуңа күрә, Аллаһы Тәгалә корәйшиләргә Үзенең барлыгын-берлеген танып, йортын пакьләп гамәл - гыйбадәт кылырга әмер итә. Мөхәммәд әл-Мостафа (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм):

عَنْ اَبِي هُرَيْرَةٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ:

اَلْمُلْكُ فِي قُرَيْشٍ، وَ الْقَضَاءُ فِي الْاَنْصَارِ،

وَ الْاَذَانُ فِي الْحَبَشَةِ

«Падишаһлык - корәешләргә, казыйлык - әнсарларга, мөәзинлек - хәбәшиләргә», - дип әйтеп калдырган. Әйткәннең мәгънәсе: киләсе буыннар шунысын

да белсен: мөселман өммәтенең җитәкчеләре корәйшиләрдән булырлар. Корәйшиләр Мөхәммәд (галәйһис-сәлам)нең пәйгамбәрлеген ничә еллардан соң гына таныдылар.

## ГАРӘП КАВЫМЫ ХАКЫНДА ХӘДИС-ШӘРИФЛӘР

Гарәпләр хакында Рәсүлебез (салләл - лаһү галәйһи вә сәлләм) күп хәдисләрендә сөйләп китә. Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм)нең шулай эшләүе бер дә гаҗәп нәрсә түгел. Үзе гарәп булып, үз халкын сөйгән, ватанпәрвәр булган. Бу хәдис - шәрифләр чын, асыл гарәпләр нинди, алар нинди булырга тиеш икәнлекне ачыклыйлар.

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُما قالَ:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ :

أَحِبُّوا الْعَرَبَ لِثَلاثٍ:

لِأَنّي عَرَبِيٌّ ، وَ الْقُرْءان عَرَبِيٌّ ،

وَ كَلامُ أَهْلِ الْجَنَّةِ عَرَبِيٌّ



www.darul-kutub.com

* Гарәпләрне өч нәрсә өчен яратыгыз:
— минем үземнең гарәп булуыма,
— Коръәннең гарәпчә булганына,
— җәннәт халкының җәннәттә телләре гарәпчә булганга күрә.

عَنْ أَنَسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قالَ:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ :

حُبُّ قُرَيْشٍ إِيمانٌ وَبُغْضُهُمْ كُفْرٌ،

وَ حُبُّ الْعَرَبِ إيمانٌ وَبُغْضُهُمْ كُفْرٌ،

فَمَنْ أَحَبَّ الْعَرَب فَقَدْ أَحَبَّــنِي،

وَ مَنْ أَبْغَض الْعَرَب فَقَدْ أَبْغَضَنِي

* Корәйшиләрне ярату — иманнандыр, аларны күрә алмау исә — көферлектер, кем дә кем гарәпләрне яратса — үземне яраткан булыр, кем дә исә гарәпләрне күрә алмаса — үземне күрә алмаган булыр.



www.darul-kutub.com

عَنْ جابِرٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ

أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قالَ:

إذا ذلَّتِ الْعَرَبُ ذَلَّ الْإسْلامُ

* Гарәпләр түбәнсетелсә — Ислам дине дә түбәнсетелгән булыр.

عَنْ طَلْحَة بن مالِكٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ

أنْ قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ :

مِنِ اقْتِرابِ السَّاعَةِ هَلاكُ الْعَرَبِ

* Кыямәт җитүгә дәлилләрнең берсе — гарәпләрнең һәлак булуы.

عَنْ أَنَسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ :

اَلسَّبَّاقُ اَرْبَعَةٌ: اَنَا سَابِقُ الْعَرَبِ



www.qaruh-kutub.com

وَبِلَالٌ سَابِقُ الْحَبَشَةِ

وَسَلْمَانُ سَابِقُ فَارِسٍ

وَصُهَيْبٌ سَابِقُ الرُّومِ

* Җәннәткә иң алда керүчеләр дүртәү булыр:
— гарәпләрдән иң беренче буларак мин керермен, фарсылардан — Сәлман, хәбәшиләрдән — Билал, румнардан исә — Соһәйб.

Бу хәдисләрне хәзрәти Ибне Хәҗәр әл-һәйсәми үзенең гарәпләргә багышланган китабында китерә. Әлбәттә, без һәркайсыбыз Пәйгамбәребез (салләллаһү галәйһи вә сәлләм)не дә, Коръәннең телен дә, җәннәттә, Аллаһ насыйп итсә, сөйләшәчәк телебезне дә яратабыз да, хөрмәтлибез дә. Гарәп кавымы турында сүз барганда исә Аллаһы Раббыбызның әл-Хүҗүрат сүрәсенең 13 аятен истә тотарга тиешбез:

يَٰٓأَيُّهَا ٱلنَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَٰكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ
وَجَعَلْنَٰكُمْ شُعُوبًا وَقَبَآئِلَ لِتَعَارَفُوٓا۟ ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ
عِندَ ٱللَّهِ أَتْقَىٰكُمْ ۚ إِنَّ ٱللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ١٣



www.darulkutub.com

«Ий, кешеләр! Без сезне ир белән хатын буларак яраттык. Бер - берегезне белеп таныр өчен сезне халыклар һәм кабиләләрдән булдырдык. Арагыздан Аллаһ каршысында иң хөрмәтлегез — иң тәкъва булучыгыз! Хакыйкатьтә, Аллаһ — белүче, хәбәрдар!»

Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм), Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, башка милләт кешесе булсада иң күркәм холык иясе булыр иде. Әмма Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм) Аллаһы Тәгаләнең әмере белән гарәп, корәйши, һәшими булган. Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм)не хак, чын сөю белән сөергә, яратырга тиешбез. Аны ярату - Аллаһы Тәгаләне ярату белән бер. Аллаһы Тәгаләне ярату һәм Аның хәбибе Мөхәммәд ( галәйһис - сәлам) не чын, ихлас күңел белән ярату - җәннәт әһеле булырга сәбәптер, ин шәә Аллаһ.

Шуның белән Пәйгамбәребез (салләл-лаһү галәйһи вә сәлләм)нең милләте, нәселе, нәсәбе,исемләре турында сүзебезне тәмамлыйбыз.Аллаһы Раббыбыз без, мөскен, фәкыйрь бәндәсеннән бу эшебезне кабул итсә иде, китапны укучыларыбызга бу әсәрдән файдалар күреп башкаларга җиткерергә насыйп булса иде дип дога кылып калабыз. Амин, амин, амин, йә Раббәл - Галәмин!



www.darul-kutub.com